**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«23» 10 2024 ел Яр Чаллы № 4782

«2021 елга ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү нигезләмәсен һәм еллык планын раслау турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» 2009 елның 27 ноябрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 100-ТРЗ номерлы Закон) 4 статьясы 3 пункты нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү нигезләмәсен һәм еллык планын раслау турында» 2021 елның 23 мартындагы 866 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «...2023 елга» сүзләрен «...2024 елга» сүзләренә алыштырырга.

1.2. 2023 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү планын 2 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Комиссия составыннан чыгарырга:

- Л.В. Рафикованы.

1.4. Комиссия составына кертергә:

- Батыршина Гөлназ Расият кызын – «Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча ТР Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ департаментының гражданнарны беренчел кабул итү башлыгы.

1.5. Комиссиянең түбәндәге әгъзаларының вазыйфаларын үзгәртергә:

- Низамиева Эльмира Роберт кызы – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;

- Мадярова Дамира Әмирҗан кызы – Башкарма комитетның төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече.

2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 23.10. 4782 номерлы карарына 2 кушымта

## 2024 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү планы

**Тикшерүләр үткәрү максаты:** Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле.

| № | Ведомство буйсынуындагы оешманың исеме | Ведомство буйсынуындагы оешманың урнашу урыны | Тикшерү үткәрүнең формасы (документар яки күчмә) | Планлы тикшерү үткәрү чоры | Тикшерү үткәрү срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Тукай муниципаль районы, Калмия авылы, Молодежная ур., 24. | Документар | 2024 елның IV кварталы | 20 эш көне |
| 2 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Тукай муниципаль районы, «Татарстан» совхозы пос., Школьная ур., 18. | Документар | 2024 елның IV кварталы | 20 эш көне |

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 23.10
4782 номерлы карарына 3 кушымта

**Ведомство контроле буенча чаралар үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

**Комиссия рәисе:**

Хәбибуллин А.Р. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе;

**Комиссия әгъзалары:**

1. Бузина Н.К. – Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы;
2. Низамиева Э.Р. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
3. Мадярова Д.Ә. – төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече;
4. Гыйлаев Ф.М. – координация советы рәисе, АПК хезмәткәрләре профсоюз комитетының Тукай районы комитеты рәисе;
5. Хәбетдинова Г.Ф. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгының укыту эшләре буенча урынбасары;
6. Муленкова В.Р. – «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе;
7. Батыршина Г.Р. – «Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча ТР Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ департаментының гражданнарны беренчел кабул итү башлыгы;
8. Потеев М.А. – Тукай районы үзәк хастаханәсе баш табибы.